СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

4 ноябрь, 1998 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 126 (8283) | Бәясе билгеләнгәнчә

**Район хакимиятендә**

## СҮЗ БИК ҖИТДИ БУЛДЫ

***Хакимияттә уза торган киңәшмәләрнең берсе дә теге яки бу мәсьәләгә җиңелчә генә мөнәсәбәттә үтми. Әмма хакимият башлыгы Ф.С.Сибагатуллин Казанда булып узган республика киңәшмәсеннән кайткач шимбә көнне хуҗалык рәисләре, предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләре белән үткәргән бу киңәшмә тикшерелгән мәсьәләләрнең дә, аларга карата мөнәсәбәтнең дә гаять җитдилеге белән аерылып торды.***

Фатих Сәүбәнович сүзенең башында ук алга таба ничек яшәвебез беренче чиратта һәм бары тик үзебездән генә торуына басым ясап, илдәге һәм республикадагы икътисадый - финанс кыенлыкларының безне дә читләтеп үтмәвенә һәм бу шартларда бары тик җитештерүне баръяклы үстерү, һәр участокта ныклы тәртип булдыру, һәркемдә башкару дисциплинасын һәм шәхси җаваплылык хисен ныгыту юлы белән генә тотрыклылыкка ирешергә мөмкин булуын җитди искәртте. Ә бу таләпләр тормышыбызның җитештерү өлкәсенә дә, социаль һәм башка сфераларына да бердәй кагыла. Шуңа да хакимият башлыгы киңәшмәдә районның киңъяклы тормышының барлык өлкәләренә дә күпмедер дәрәҗәдә кагылып үтте. Һәм моңа нигез дә җитди.

Кайсы гына тармакны алсаң да, эш ахыр нәтиҗәгә, ахыр чиктә, халыкның тормыш хәлен ничек тә җиңеләйтү мәсьәләсенә кайтып кала. Беренче чиратта ул районның бюджетын формалаштыруга, бюджетка салым түләргә тиешле предприятие һәм оешмаларның бу эшне ничек башкаруларына килеп терәлә. Шуңа да Ф.С.Сибагатуллин моннан ары бу мәсьәләдә беркемгә дә ташлама ясалмаячагын бик нык иттереп әйтте. Чыннан да, район казнасына иң зур өлешне кертүче нефтьчеләрнең үз хәлләре дә бик авыр булуын күреп торабыз, зур һәм күп кешеле предприятиеләрдән булган шикәр заводы да шикәр чөгендере эшкәртү сезонын гомер булмаганча иртә төгәлләде, ә заводның җылылык үзәгеннән тулы бер поселок йортлары җылытылуын исәпкә алсак, хәлнең кискенлеген чамалавы кыен түгел. Шуңа да ел ахырына кадәр барлык түләүчеләрнең дә бюджетка бурычларын кертеп бетерүләре шарт. Ә бюджет сферасындагыларга хезмәт хакы, пенсионерларга пенсия түләүнең чыганагы бер генә бит. Хакимият башлыгы нәкъ менә соңгысына аерым басым ясап, заманында шушы пенсионерлар кулы белән булдырылган матди байлыкларны кабул итеп алып, бүген шул карт - карчыкларга пенсияне дә вакытында биреп бара алмавыбыз өчен безгә алар алдында оят булырга тиеш бит дип искәртеп үтте. Ә матди байлык һәм аңа мөнәсәбәт мәсьәләсе киңәшмәдә авыл хуҗалыгына кагылышлы аспектта аеруча кискен күтәрелде. Агропромышленностьта яшәү чыганагы бер генә - продукция җитештерү һәм аны сату күләмен арттыру, һич югында тотрыклы саклау. Ә бу беренче чиратта малларның баш санын киметми кала алган тәкъдирдә генә мөмкин. Кызганычка каршы, күп кенә хуҗалыкларда мөгезле эре терлекләрнең баш санын кискен киметүгә юл куйдылар, нәтиҗәсе иң тиз күренә торган һәм төшемле тармак булган дуңгызчылыкка да игътибар һәркайда да җитәрлек түгел. Хакимият башлыгы бу өлкәдә начар эшләүче хуҗалыкларның һәркайсына аерым - аерым тукталып үтте һәм гаять мөһим бу эшләргә җиңел караучы җитәкчеләргә шактый нык кызарырга туры килде. Ф.С.Сибагатуллин бу мәсьәләләрне матбугат битләрендә дә кыюрак күтәреп чыгу зарурлыгын һәм моның уртак эшкә файда гына булачагын искәртеп үтте. Хакимият башлыгының беренче урынбасары - авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе начальнигы Ф.М.Дәүләтшинның чыгышы да күп хуҗалыкларда терлекчелеккә, бигрәк тә сөт җитештерү һәм хәзерләүгә игътибар йомшаруы уңаеннан җитди борчылу белән сугарылган иде. Ул җәһәттән хакимият башлыгы сыерларның продуктлылыгын тотрыклы саклау белән беррәттән сөт сатуны ничек кенә булса да арттыру, шулай итеп хезмәт хакы түләргә акча эшләү һәр җитәкче алдында торган мөһим бурыч булуын ассызыклап үтте. Ул берочтан бу мәсьәләдә күзбуяучылык белән шөгыльләнмәскә дә киңәш итте. Бер үк вакытта ул халыктан сөт сатып алу эшен дә күз уңыннан җибәрмәскә кирәклеген искәртте.

*(Ахыры 2нче биттә).*

## ГӘЗИТСЕЗ НИЧЕК ЯШИСЕҢ ДИ ИНДЕ УЛ...

Элек, көз җитсә, вакытлы матбугатка язылу башлана торган иде. Менә берничә ел инде ул эш ярты ел саен уздырыла, кайсы басмаларга ел дәвамында да язылырга була. Бу юлы исә, каталогларга кертелгән басмаларның бәясе кимендә өч тапкыр үзгәрү сәбәпле, язылу сроклары күчте. Аннары, инде телгә кергән өч процентлы өстәмә бетерелсә дә, газета - журналларның бәясе шактый югары бу юлы. Кыскасы, язылу кампаниясенең старты бик сүлпән булды, анысына халыкның акчасызлыгы да җитди сәбәп. Мисал өчен күпләр яраткан газеталары "Комсомольская правда"сыз да калыр ахры - 105 сум урынына 209 сум 40 тиен түлисе бит. Республикада иң популяр булган күп тиражлы "Татарстан яшьләре"нә бәя дә нәкъ ике тапкыр артып, 60 сумга менгән. "Республика Татарстан", "Вечерняя Казань" газеталары 8 - 9 сумга кыйммәтләнгән. Башка басмалар да я бәяне бераз арттыралар, я чыгу ешлыгын үзгәртәләр. Әнә, атнага биш чыгып килгән "Казанское время" көздән бирле берәр генә чыга бит инде. (Дөрес, 8 битле булып).

Ничек кенә булмасын, вакытлы матбугатка язылу бара анысы. Нурлаттагы үзәк почта бүлегендә көн саен 40 - 60 кеше язылып китә. Гәрчә,- дип аңлата оператор Марина Иванова, - күпләр инде 6 айга түгел, ә 3 айга гына языла. Абунәчеләр беренче чиратта барыбер район газетасына язылалар - район тормышы турында да күп яза "Дуслык", атналык телепрограмманы да биреп бара, хакы да бик зур түгел - 25 сум 20 тиен.

Матбугатка язылуның актив баруы турында элемтәчеләр үзләре дә кайгырталар - почта хезмәткәрләре бу эшкә бөтен коллектив белән кушылганнар. Яздыру планын киметмәгәннәр, шуңа күрә хат ташучылар почта өләшергә чыкканда яздыру квитанцияләрен калдырмыйлар. Ә шәһәрдәге 2нче элемтә бүлеге хезмәткәрләре геофизикага, НГДУ ОРСына, балалар бакчасына барып яздыртырга да иренмәгәннәр.

- Быелгы кампаниядә дә без былтыргы кебек кредитка яздыру практикасын кулланырга мөмкин дип саныйбыз,- ди РУПС начальнигы Владимир Петрович Сибулатов.- Бу очракта абунәче тиешле сумманы 2 - 3 ай эчендә түли. Анысына үзебез дә аптыраганнан риза булабыз инде, әмма беренче чиратта халыкка уңайлы булсын дип шулай эшлибез.

Элемтәчеләр язылу кампаниясенең барышына әледән әле йомгак ясап торалар. 2нче ноябрьгә булган мәгълүматлар шәһәрдә һәм район авылларында 1031 данә - үзәк, 1586 - республика матбугаты һәм 2622 данә район газетасы яздырылуын күрсәтә - барлыгы 5239 данә. Элекке елларда районда 36 мең чамасы, ягъни һәр кешегә 0,7 басма яздырыла торган иде.

... Матбугатка яздыручы оператор янында каталоглар тезеп куелган, әмма чират юк диярлек - 1 - 2 генә кеше. Бер абунәче "Аргументы и факты", "Здоровье" һәм "Дружба"га язылуын әйтте. Акча юк дип күпме генә зарлансак та, киләчәккә өмет ничек кенә сүрән булса да, кеше барыбер җан азыгыннан башка тора алмый шул...

**Т.НАЗАРОВА.**

**«ДУСЛЫК»КА ЯЗЫЛУ БАРА**

***1999 елның беренче яртысы өчен "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасына язылу бәясе - 25 сум 20 тиен. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Әфган сугышында булучыларга, Чернобыль атом электр станциясендәге фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга тиешле документлар нигезендә 50 процент ташлама ясала.***

**Басылганга кире кайтып**

## ГАЗ КЕРӘСЕНӘ ӨМЕТ БАР

***"Дуслык" газетасының 117нче (14нче октябрь 1998 ел) санында "Онытылган авыл" дигән баш астында Иске Иглай авылында яшәүчеләрнең хаты басылып чыккан иде. Хат авторлары авылга газ кертүнең бик акрын темпларда баруыннан зарланып язганнар. Район хакимияте тарафыннан бу мәсьәләгә ачыклык кертү, ягъни авылны газлаштыру эшләрен тизләтү "Нурлатгаз" ЭПУсы карамагына тапшырылды. Редакция "Нурлатгаз" ЭПУ сы начальнигы Р.Ә.Хәсәнов һәм "Рассвет" КХАсы рәисе Ә.Н.Рәхмәтуллин белән элемтәгә кереп түбәндәгеләрне ачыклады.***

Ике - өч ел элек Иске Иглай авылына газүткәргеч төзелә. Ул урамнарга да, өйләргә дә суузылган була. Ләкин КХА рәисе Ә.Н.Рәхмәтуллин әйтүенчә, 30 мең сумнан артык акча җитмәгәнгә, подрядчылар - Димитровград шәһәренең 14нче МСУсы эшне ахырынача җиткермичә Якты Күлгә күчкәннәр.

Бүген, "Нурлатгаз" ЭПУсы начальнигы Р.Ә. Хәсәнов Иске Иглайны газлаштыру эшләре буенча шактый гына җитешсезлекләрне билгеләде. Аерым алганда, тышкы күренеше буенча терәгечләр һәм газ торбаларының ялганган урыннары гамәлгә яраксызга чыгарылды.

Шулай ук өйләрдә контроль приборларыннан газ приборларына кадәр монтаж төгәлләнмәгән, форточкалар һәм төтен юллыклары да ясалмаган, газ үткәргечләр буялмаган.

Соңгыларына килгәндә, болары - йорт хуҗалары гаебе икәнен дә танырга кирәк. Гомумән, газ керүне көтеп хуҗаларның күпчелеге аны кабул итүгә артык әзерлек алып бармаганнар диярга мөмкин. Аннары урамнарда газүткәргечләргә карата да карашның сакчыл булмавы ачыкланды: анда - санда терәгечләрне транспорт аударып сындырган, кайберләрен алып китә дә башлаганнар инде.

Район хакимияте башлыгы урынбасары Н.Б. Мөлеков бу мәсьәләнең конкрет вакытта хәл ителәсенә, төгәлрәге, бүлү шкафына һәм авылның беренче йортларына табигый газның 10 көн эчендә киләчәгенә ышаныч белдерә.

***P.S.** Район хакимияте башлыгы Иске Иглай авылы халкының хат - мөрәҗәгатен карауны редакциянең озакка сузганлыгын күрсәтте. Редакциянең җаваплы хезмәткәре моның өчен тиешле җәзага тартылды.*

## МӘГАРИФ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

* **Т**атарстан бизнеска җәләктәшлек институты каршындагы икътисадый - хокукый колледжның Нурлаттагы филиалында көзге семестр башланды. Монда 1 - 2 курста укучылардан биш төркем институт белгечләренең лекцияләрен тыңлаячаклар, фәнни хәзерлек алачаклар. Укулар 9 ноябрьгәчә дәвам итә.

* **Б**ыелгы уку елы республикада балалар сәламәтлеген кайгырту елы дип игълан ителгән иде. Узган атнада ДЮКФП базасында район мәктәпләренең физик тәрбия укытучылары катнашында уздырылган семинар - киңәшмәдә дә сүз нәкъ менә шул хакта барды. Сәламәтлек дәресләрен уздыру һәм аларның кыйммәте, физик тәрбия укытучыларының хезмәтен бәяләү тәртипләре турында район мәгариф бүлеге мөдире урынбасары В.М.Камалова чыгыш ясады. Бүлек методисты Ә. Ә. Нәбиуллин сәләтле балалар белән эшләү һәм аларның мөмкинлекләрен тагын да үстерү шартлары турында сөйләде.

**С**еминарның гамәли өлешендә укытучылар баскетбол (тренер Ф.Н. Сафин) һәм көрәш (Р.Ә.Рәхмәтуллин) буенча ачык дәресләр карадылар.

## Кеше һәм табигать

# УРМАН АКСАКАЛЫ



Татарстан Республикасы урман хуҗалыгының атказанган хезмәткәре, Вишневая Поляна урманчылыгы егере Василий Сергеевич Варламов: "Аучылык - кеше белән табигать арасындагы мөнәсәбәтләрнең иң дөрес күрсәткече ул. Әгәр аучылык кимесә, димәк табигый тигезләнеш югалган һәм ашыгыч чаралар күрергә кирәк дигән сүз",- дип кабатларга ярата. Аның бу сүзләре, һичшиксез, дөрес. Үзенең 70 еллык гомереннең 30 елын ул урман каравылчысы, ә 20сен егерь булып эшләгән. Әлбәттә, ул күптән инде пенсия яшендә, әмма үзен әле хәзер дә сау - сәламәт һәм көр күңелле итеп тоя. Иң мөһиме - аның гаять зур һәм кыйммәтле тәҗрибәсе, урманны һәм анда яшәүчеләрне җентекләп белүе. Менә бу сыйфатлар аның эше өчен бик кирәкле һәм алар сирәк кешедә очрый. Татарстан урман хуҗалыгы идарәсе аңа 3 мең гектар мәйдандагы урманга һәм 200 гектардагы сулыкларга (Чирмешән елгасы һәм күлләргә) күзәтчелек итүне йөкләгән.

Әлбәттә, бер генә егерь шушы кадәр территорияне карап бетерә алмас иде. Ул үзенең ирекле ярдәмчеләренә - аучыларга таяна, аның кулы астында 60лап кеше исәптә тора.

Егерьның төп бурычы - үзенә тапшырылган хуҗалыкта тере һәм тере булмаган табигать балансын акыллы рәвештә саклау. Һәм монда күп нәрсә егерьның инициативалы булуына, табигый запаслар саекмасын өчен аның эшне оештыра белүенә бәйле. Әйтик, мисал өчен, су кошлары үрчесен өчен нинди шартлар тудырырга кирәк? Хуҗалыкта җитәрлек күләмдә күлләр бар. Егерь үзенең ярдәмчеләре белән үз көне бульдозерлар ярдәмендә әлеге сулык тирәсендә туфракны күтәртә төшә һәм шуның белән яз көне ташу суларының җыелып калуын тәэмин итә. Күлләр су белән туенып калгач, кыргый үрдәкләр, казлар һәм хәтта аккошлар язын шунда кайтып оя ясыйлар һәм үзләренә туену урыны табалар. "Әй беләсезме, - ди Василий Сергеевич,- браконьерлар көрәк белән канау казып су агу өчен юл ясыйлар да, шунда балыкка тозак куялар, ә балыкның нәкъ менә уылдык чәчкән чагы була. Шулай итеп, браконьерлар табыш ала, ә җәй көне күлдә бер генә маймыч та күрә алмыйсың". Әйтик, кыш көне пошилар усак кайрысы ашыйлар, тал ботаклары белән туеналар. Ә менә кабаннар ничек тамак туйдыра соң? Аларга да кеше ярдәмгә килә. Егерь үзенең ярдәмчеләре белән бөртек калдыклары, чөгендер, бәрәңге куеп чыга. Кабаннар салкыннан һәм җилдән качып тирән чокырларда кышлыйлар, ләкин теләсә нинди чокырда түгел, ә нәкъ менә камыш үсә торган (үлән тамырлары булган) сазлыклы җирләрдә. Ә кыш дәвамында аларга дигән азыкны чаналар белән алып килеп, аерым урыннарга куеп калдыралар. Кабаннар аларны килеп ашыйлар. Язын һәм көзен ашау урыннарына тоз да сибелә.

Егерь һәм аның ярдәмчеләре бүреләргә карата аяусыз. Әлеге ерткыч көтүе бер кышта гына да бу тирәләрдә 10ар яшь пошины һәм дистәләгән кабанны, тагын да күбрәк кыр кәҗәсен һәлак итәләр. Ә менә хәзерге вакытта Варламов карамагындагы җирләрдә бүреләр юк, узып баручы берәрсе ялгыш килеп керсә генә. Аның каравы, урман мәчесе бар.

Василий Сергеевич белән без күптәннән таныш. Ул урман каравылчысы булып эшләгән чаклардан бирле. Аның белән танышканнан соң: бу кеше аучы булып туган дигән фикергә киләсең. Энергияле, тынгысыз һәм шул вакытта бик күзәтүчән. Гомере буе табигатьне яраткан һәм югары бәяләгән, урманны һәм анда яшәүчеләрне яхшы белә һәм аудан табышсыз кайтса да үзен бәхетлегә саный ала. Эчкерсезлеге, күңел җылысы, бик арыган вакытында да шаян һәм елмаючан булуы кешеләрне үзенә тартып тора. Авылдашлары аның турында: "Варламовның башы саф, күңеле чиста аның. Аны яратмый мөмкин түгел",- диләр.

Тәҗрибәле аучы Василий Варламовның урман алдындагы хезмәтләре бәяләнми калмады. Ул "Дәүләт урман хуҗалыгын саклауда бик яхшы хезмәт иткәне өчен" билгесе белән өч тапкыр бүләкләнгән. Хезмәттәшләре арасында да дәрәҗәсе зур. Ә браконьерлар аның исемен ишетергә дә теләмиләр, чөнки ул аларга карата бик рәхимсез. Егерь Варламовның хатыны Тамара Александровнаның 12 ел инде урман каравылчысы булып ире белән бергә эшләве турында бик аз кеше беләдер. Нечкә җанлы хатын - кыз өчен гаять авыр хезмәт, ләбаса, бу! Әмма ул иренең һәр адымында ышанычлы терәк һәм ярдәмче булып тора. Гаиләдә үскән өч кыз да әти - әниләренең мәшәкатьләренә битараф булмадылар. Ә хәзер җәй буена аларга булышырга дип оныклары кайталар. Оныклары - алар өчен иң зур шатлык.

**В.КОМОЛОВ.**

***Рәсемдә: менә ул Вишневая Поляна урманчылыгының куркусыз егере В.С.Варламов. Аны күптән түгел булып үткән 70 яшьлек юбилее һәм 50 ел дәвамында урманга хезмәт итүе белән чын күңелдән котлап, Василий Сергеевичка сәламәтлек, иминлек һәм йөрәгендәге изге утның сүрелмәвен телибез. Шулай яшә, урман аксакалы!***

# ОЯТ - ТӨТЕН ТҮГЕЛ, КҮЗНЕ ӘЧЕТТЕРМИ

**Көн кадагына**

Янгын службасы халыкка районда килеп чыккан теге яки бу зур янгын очрагы турында белгертә торган язмаларда (арып та беткәннәрдер инде) юл аралаш урыннарда янгыннарны кисәтү һәм сүндерү үз вазифаларына кергән кешеләр адресына урынлы үпкә белдерелүен дә чамаларга мөмкин. Һәм әледән әле күренгәләп тора торган бу язмалар ул кешеләрнең, кем әйтмешли, бер колакларыннан керсә дә икенчесеннән чыгып китә төсле. Шулай булмаса, соңгы вакытта янгыннар шулай еш һәм шактый зур зыян китерер идемени.

Тугыз айда авыл җирендә торак секторда чыккан 40 янгынның күпме зыян китерүен йорт, мунча яки сарайның бәяләмә кыйммәтен генә белгән һәр кеше бик җиңел исәпләп чыгара ала. Ә шушы вакыт эчендә агропромышленность комплексы объектларында булган 8 янгын китергән зыянның күләме тагын да зуррак - янгын часте биргән мәгълүматлар буенча - 3 мең 243 сум.

Бу саннар: янгыннар гадәттән тыш хәлдән гадәтигә әверелеп бара, ә, ут чыгуның иң киң таралган сәбәбе "электр үткәргечнең төзексезлеге" икәнлеген искә алсак, янгыннарга котылгысыз нәрсә дип карау бугай дип уйларга нигез бирә. Тик бу котылгысызлыкны башка сыйдыруы гына кыен: утта былтыргы чүп - чар түгел, ә мөлкәт яна бит! Урыннардагы властьларны борчыймы икән бу хәл? Аларның утка каршы торырлык власть вәкаләтләре бармы икән?

Сүзне соңгысыннан башларга кирәктер. Кагыйдә буларак, янгын чыгу куркынычы зур булган чор җиткәндә хакимият башлыгы җирле үзидарә Советлары рәисләренә, хуҗалыклар, предприятиеләр һәм оешма - учреждениеләр җитәкчеләренә янгыннарны профилактикалау һәм ут сүндерү чаралары белән тәэмин итүне йөкләгән махсус карар чыгара. Һәм ул карарда санап кителгән чаралар арасында урындагы кешеләрдән бернинди өстәмә акча эзләп табуны да сорамаган (хәзер үзләренең эшлексезлекләрен гадәттә акча юклыкка сылтыйлар бит), ә бары тик башкару дисциплинасын гына күздә тоткан пунктлар да бар. Аерым алганда, җирле үзидарә Советлары, торак - коммуналь идарәләр һәм бүлекләрнең янгынга каршы агитация - пропаганда эше алып барулары сорала. Һәм нәрсә? Янгын службасында кайда да булса гражданнарны янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә өйрәтү оештырылуына бер генә мисал китерергә дә авырсындылар, бәлки кайдадыр янгынчыларны да чакырып гражданнар җыены булгандыр, яки халыкның саклык чаралары күрү - күрмәве, йортларда ут сүндерүнең беренчел чаралары булу - булмавы тикшерелгәндер. Бәлки янгынга каршы ирекле дружиналарга булышлык итүдә анык системаның берәр үрнәге бардыр? Булса бик ярар иде дә шул...

Һәм янгынчылар ут китергән зыянның гаять зур булуын элеккечә үк "урыннардагы янгынга каршы ирекле җәмгыятьләрнең сугышчан әзерлеге гадәттән тыш түбән һәм матди - техник базасы зәгыйфь булудан" дип саныйлар. Мисал өчен, "Киекле", "Сөлчә", сөт - май комбинаты, нефтебаза, "Агрохимсервис", РСУ ярдәмче хуҗалыкларында янгын сүндерү техникасы юк дияргә мөмкин. Ә техника булмагач ( яки ул төзек түгел икән), тәүлек буе дежурлык оештыруның нинди мәгънәсе бар? дип саныйлар бу хуҗалыкларның җитәкчеләре.

Бу урында моннан өч еллар элек Киекледәге төзелеш материаллары складында чыккан янгынны искә төшерәсе килә. Ничек куәтле булды бит ул янгын. Ул чакта бер гөнаһсызга зыян күргән кешеләрнең күңелләрендәге төер һаман да бетмәгән, төтен һаман да "күзләрен" әчеттерә әле. Төтене бик көчле булганга бит бу...

**Д.ТӘМАЕВА.**

# ИМИНЛЕК ҮЗЕБЕЗГӘ БӘЙЛЕ



***Шушы көннәрдә автотранспортчылар бәйрәме алдыннан ике УТТ шоферының фаҗигале төстә, юл - транспорт һәлакәтендә вафат булуы бөтен коллективны тетрәтте. Һәлакәт алар гаебе аркасында килеп чыкмаса да, шофер һәм җәяүле дә үз - үзенә, тирә - ягындагыларга таләпчән, өйрәнүчән караш белән күз салырга, төптән уйланырга мәҗбүр булды. Юлда йөрү кагыйдәләренә электән үк үтә җаваплы караштa торган УТТ һәм шулай ук район ЮХИДИ җитәкчелеге дә бәла - казадан саклануның бөтен чараларын күрү максатында бу хакта аерым сүз алып бардылар. 5нче колоннадагы җыелыш нәкъ шул мәсьәләләрне алга куйды. Бу рәсемнәр шул көнне төшереп алынган иде.***




**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

# МИНИ - ФУТБОЛ

29 октябрьдә ДЮКФП спорт комплексында балалар - яшүсмерләр спорт мәктәбе (ДЮСШ) командалары арасында мини - футбол буенча турнир булып үтте. Яшь футболчылар арасында көрәш киеренке барды, һәркемдә җиңү теләге зур иде. Нәтиҗәдә призлы урыннар түбәндәгечә бүленде: беренче урынга ДЮСШ - 2 (тренеры Ш.Тюкаев), икенче һәм өченчегә ДЮСШ -1 (тренер - Ф.Гобәйдуллин) һәм 3нче (тренер - Р. Гайниев) командалары чыкты.



Уеннарда Александр Ундаков, Реваль Гыйләҗев, Дима Пьянзин, Евгений Петров, Сергей Семибратов үзләрен актив спортчы буларак таныттылар.

**Ш.ТЮКАЕВ.**

*Әдәплелек дәресләре*

# «ИСӘНМЕСЕЗ, САУМЫСЕЗ!..»

Без һәрвакыт кешеләр арасында яшибез: өйдә - якыннарыбыз, туганнарыбыз, җәмгыятьтә дусларыбыз һәм хезмәттәшләребез арасында булабыз: аларның кайсы бик яхшы таныш, ә кайсын аз беләбез. Болары белән эштә, укуда, кунакта очрашабыз. Ә инде урамда, автобуста, театрда, кинода, музей һәм китапханәләрдә, поезд һәм самолетта - кыскасы һәркайда һәм һәрвакыт таныш түгел кешеләр белән аралашырга туры килә. Кайчандыр Марк Аврелий болай дигән: "... син үзеңне кешелек дөньясының тормышыннан аерып карый алмыйсың. Син шунда яшисең һәм кешелек өчен яшисең. Куллар, аяклар, күзләр кебек үк без бер - беребезгә үзара тәэсир итеп яшәр өчен яратылганбыз". Без еш кына: җәмгыятебездә игелеклелек җитми, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә эчкерсезлек юк, үзара аралашу культурабыз бик түбән: кешеләр бер - берсенә игътибарсыз һәм битараф, еш кына тупаслык, тәрбиясезлек күрсәтәләр, күпләре зәвыксыз киенә, үзенең туган телендә дә дөрес һәм матур итеп сөйли белми, дип зарланабыз. Ә үзебез соң? Үзебезне башка кешеләр белән, төрле хәлләрдә ни рәвешле тотуыбыз турында уйлаганыбыз бармы икән? Без аларны ихтирам итәбезме, хәлләренә керәбезме, иплән кенә ярдәм күрсәтәбезме соң? Һәркайсыбыз үз тәҗрибәсеннән чыгып беләдер: кем дә булса этсә яки төртсә (ялгыш кына булса да) һәм гафу үтенмәсә, бик тә ачу килә; яки кем дә булса тупас сүз әйтсә, әгәр сезнең арыганыгызны күреп автобуста урын бирмәсәләр, яки бик кәефсез чагыгызда урынсыз шаярта башласалар, шулай ук кәеф кырыла. Чөнки бу очракларда иң гади әдәп кагыйдәләре бозыла. Әлбәттә, бүгенге заманда күп нәрсә үзгәрә, тулылана, ниндидер кагыйдәләр үткәндә кала, әмма аларның бер өлеше традицион рәвештә күп гасырлар дәвамында сакланып килә.



Әйдәгез әле шуларның берсе - сәламләшү турында гына сөйләшик.

Кешеләр бер - берсе белән очрашканда беренче сүз итеп: "Исәнмесез!" диләр.

"Исәнмесез!" - азмы бу, әллә күпме? Бер яклап караганда, күп тә түгел кебек, чөнки берниндиде яңа мәгълүмат тапшырылмый бит. Ә икенче яклап, әгәр каршы яктан сәламләү булмаса, теләсә кем моңа бик тә гаҗәпләнә һәм рәнҗи.

Дөньяда безнең өчен күп кенә сәламләшү формалары бар. Тибетлылар, мәсәлән, исәнләшкәндә уң куллары белән баш киемен салалар, сул кулны колак артына куялар, җитмәсә телләрен күрсәтәләр.

Һиндстанда кеше белән очрашканда уч төпләрен йөрәккә кую гадәте сакланган. Яңа Зеландиянең кайбер кабиләләре бер - берсенә борыннары белән терәлеп исәнләшәләр.

Кем беренче булып исәнләшергә тиеш соң? Әлбәттә, яшьләр - өлкәннәрне, кемнең дә булса кул астында эшләүче - үзенең хуҗасын, ир - ат хатын - кызны сәламләргә тиеш. Килеп кергән кеше андагылар белән беренче булып исәнләшә.

Урамда арттан килүче кеше танышын күрсә, аның янына килеп җиткәч, беренче булып сәлам бирә. Басып торучы кеше яныннан узучы шулай ук беренче булып сәламләргә тиеш.

Әгәр берәр таныш түгел кеше сезнең белән ялгыш исәнләшсә нишләргә? Сез дә сәлам бирегез һәм аның ялгышканын күрсәтмәгез.

Якын танышларың белән башны җиңелчә генә иеп яки баш киемен салып исәнләшергә дә мөмкин. Кул биреп исәнләшү безнең аңыбызда якын дуслык билгесе булып урнашкан, шуңа күрә сузылган кулны кабул итмәү кешене кимсетүгә тиң. Японлылар кешеләрнең кул бирешеп исәнләшүен берничек тә кабул итә алмыйлар.

Очрашканда кулны ничек бирергә? Беренче кагыйдә мондый: өлкән кеше - яшьрәккә, хатын - кыз - ир - атка, начальник кул астында эшләүчегә кул бирергә тиеш. Бары тик яшь кызлар гына ир - атның беренче булып кул сузуын көтәләр. Кул биргәндә аны артык сүлпән, ялкау рәвештә сузмаска кирәк. Әмма танышыңның кулын бик каты кысу, аны һавада селкү шулай ук килешми. Хатын - кыз күрешкәндә перчаткасын салмаса да ярый. Ир - атлар үзара күрешкәндә шулай ук перчаткада килеш кала алалар. Өстәл яки бусага аркылы кул биреп күрешмәгез.

Менә шул рәвешле аралашуда җылылык тудыру, һәм шуның белән үзебезнең кәефебезне көйләү һәм үзара мөнәсәбәтләрне җайлау өчен исәнләшүнең төрле алымнарын оста файдаланырга мөмкин.

**Н.ТАРАСОВА.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Түбән Нурлат авылында яшәүче **кадерле әниебез, зур әниебез Рәхилә Хәйрулла кызы Әбҗәббарованы** 60 яшьлек юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз.



Әни диеп, якты күңелең сагынып
Гел кайтабыз синең янга без.
Һәм бүген дә сиңа сәламәтлек,
Озын гомер, тыныч, имин тормыш,
Күп шатлыклар теләп калабыз.

**Изге теләкләр белән тормыш иптәше, балалары, килене, кияүләре, оныклары.**

Нурлат шәһәрендә яшәүче **кадерле апабыз Гөлсинә Гарифулла кызы Әхмәдиевага** 4 ноябрьдә 40 яшь тула. Апабызны туган көне белән кайнар котлыйбыз.



Яратканга күрә без өзелеп,
Апам диеп сиңа дәшәбез.
Ташламабыз, апам, гомер буе
Сезнең белән бергә яшәрбез.

Сәламәтлек, озын гомер, бәхет, шатлыклар теләп **сеңелләрең Нурисә, Гөлсирә, кияүләрең Хәлил, Сәлихҗан һәм балалар.**

**Нурлат район мәгариф бүлеге бухгалтериясе коллективы** баш бухгалтер **Гөлзифа Гомәр кызы Җиһаншинаны** юбилее белән кайнар котлый. Бәхет, саулык, гаилә иминлеге, эшендә зур уңышлар телибез.



*Бер үк темага*

## ЭКОЛОГИЯ - XX ГАСЫР ПРОБЛЕМАСЫ

Кешелекнең киләчәге турында алдан күрәзәлек итү бик катлаулы, ә экологик мәсьәләләр тагын да буталчыграк. 24 октябрьдә шәһәрнең 4нче мәктәбендә М.В.Кочеткова җитәкчелегендә "Кешелекнең киләчәге" дигән темага ток - шоу үткәрелде. Ул илебез һәм районыбыз экологиясенә багышланган иде һәм анда укытучылар да, укучылар да катнаштылар. Күп проблемалар турында фикер алышулар булды, иң мөһиме - аларны хәл итү буенча гипотезалар әйтелде. Бу көнне философ, эколог һәм белгечләр ролен укучылардан И.Мусин, М.Шаброва, Р.Фәррахов, Г.Төхфәтуллина, Р.Бадмацыренов башкарды. Ток - шоуда катнашучыларны бик күп мәсьәләләр кызыксындыра иде. Җәмгыять биосферага зыян китермичә аңа яраклашу өчен нишләргә тиеш? Пычраклык дәрәҗәсен киметү, ресурсларны экономияләү өчен нишләргә? Халык санын арттыруга карата нинди мөнәсәбәттә булырга? Һәм башка бик күп мәсьәләләр турында сөйләштек, бәхәсләштек без бу көнне... Әлеге чара вакытында без экология турында күп яңалыклар белдек. Мондый очрашулар мәктәптә соңгы тапкыр булмас, дип ышанасы килә.

**О.ПЕТРОВА.**
**4нче урта мәктәп.**

## БЕЗ ЯШӘРГӘ ӨЙРӘНӘБЕЗ

Күптән түгел бездә 5 - 7нче класс укучылары Н.Н. Крайнова җитәкчелегендә табигать кочагына экскурсиягә бардылар. Башта без төньякка юл тоттык. Юлда безгә чокырлар, инеш очрады, ниһаять, без урманга да барып җиттек. Учак яктык, шалаш кордык, көлгә күмеп бәрәңге пешердек. Телне йотарлык булды!

Өйгә дә ашыкмыйча гына, бик яхшы кәеф белән кайттык. Табигать белән очрашу елның теләсә кайсы вакытында да күңелне күтәрә.

**Н.АЛЕКСАШКИНА.**
**Богдашкино урта мәктәбе.**


## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**ГАЗ - 3307 автомашинасында шәһәр эчендә һәм шәһәрләр арасында йөкләр ташыйбыз. Әрҗәле ГАЗ - 3307не җиңел автомобильгә алмаштырам.**
Тел.: 2-12-66.

***

**Бер бүлмәле фатир биреп торам. Кормыш ягында гараж сатам.** Тел.: 5-10-29.

***

**Тышлау өчен мең данә кирпеч сатып алам.**
Тел.: 2-28-25.

***

**Минсалих Галәветдинов исеменә документлар табучының бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен сорыйбыз.** Тел.: (өй) 2-31-29, (эш) 5-17-51.

***

**Фатирлар ремонтлаучылар турында бушлай мәгълүмат бирәм. Эшне сыйфатлы итеп башкаралар.**
Тел.: 5-16-25,Нәҗип.

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга - 13нче, 27нче ноябрь көннәрендә, көндезге сәгать 11дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

### САТАБЫЗ

**Кызыл кирпеч, кыйммәт түгел.** Тел.: 2-28-65.

***

**Шәһәр үзәгендә ике бүлмәле фатир.**
Арадашчы телефоны: 2-21-53.

***

**"Таврия" автомашинасы.** Адрес: Вахитов ур., 7-10.

***

**Көнчыгыш микрорайонында йорт төзү өчен участок.** Тел.: 5-39-68.

***

**Тимер юл электр станциясе территориясендә гараж.** Тел.: 65-3-50.

***

**Электр һәм күмер самавырлары.** Тел.: 5-42-33.

***

**Декабристлар урамында 34нче йорт.** Карл Маркс ур., 4-55 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

***

**Гараж.** Адрес: Совет ур., 139-5.

***

**Гарантияле компакт дисклары белән LCX-330 музыкаль үзәге, S-90 (35 АС-212) "Радиотехника" студия колонкалары белән У-101 стерео көчәйткече.** Тел.: 2-12-51.

### САТАБЫЗ ЯКИ АЛМАШТЫРАБЫЗ

**76, 100 метр диаметрлы торбалар. Яки иткә алмаштырабыз.** Адрес: Полевая ур., 21.

***

**Кирпеч йорт. Йорт яны корылмалары, мунчасы бар. Ике яки өч бүлмәле фатирга алмаштырырга мөмкин.** Адрес: Чаллы Башы авылы, Луговая ур., 11; тел: 2-13-03.

### САТЫП АЛАМ

**Килограммын 8 сумнан бакыр, 3 сумнан җиз, бронза, 2 - 5 сумнан алюминий калдыклары.**
Адрес: Совет ур., "Татсельхозмонтаж" базасы.
А № 0204 лицензиясе.


### *РӘХМӘТЕБЕЗ ЧИКСЕЗ*

Кадерле **кызыбыз, хатыным һәм әниебез Фәһимә Шәйхетдин кызы Даутованы** югалту кайгыбызны уртаклашкан һәм мәрхүмәне җирләүдә матди ярдәм күрсәткән һәркемгә, НГДУ, УТТ, 2нче мәктәп коллективларына, 10нчы сыйныф укучыларына,туганнарга, якыннарга, күршеләргә ихлас рәхмәтебезне белдерәбез.

**Мәрхүмәнең әнисе, ире һәм кызы.**


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр:** Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.
Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә.